**ГЛАВА**
**ФОМКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ФОМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Фома ав. **КАРАР**

«14» октябрь 2025 ел № 6

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Нурлат муниципаль районының Фома авылы җирлегенә керүче Фома авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ**:

1. 2025 елның 27 октябрендә 10 сәгать 00 минутка Фома авылы, Мәктәп урамы, 15нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге Фома авылында яшәүчеләр өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.

2. Халык җыены этапларын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты белән тәэмин ителә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлегенең Фома авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

- ПУМ-4853 өчен бульдозер җайланмасы сатып алу (Беларус 82.1 тракторы базасында)
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгынга каршы инвентарь сатып алу; су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр башкару);
- һәйкәлне күчерү, ремонтлау һәм аның янәшәсендәге территорияне төзекләндерү
- Фома авылында урамнарны яктырту җайланмасы;

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Фомкино торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны кышкы карап тоту).»

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru, Нурлат муниципаль районы рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авылындагы мәгълүмат стендларында, гражданнар җыены этапларын үткәрү көненә 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Фома авыл җирлеге башлыгы Р.Х. Абдрахманов